Республика Татарстан

**СОВЕТ СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ленина, д. 60, с. Старый Мензелябаш
423354
Телефон: 4-53-46

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Ленин урамы, йорт 60, Иске Минзәләбаш
авылы 423354
Телефон: 4-53-46

***ОКПО 04311866, ОГРН 1021601312237, ИНН/ КПП 1636001393/ 163601001 ОКТМО 92253472***

**РЕШЕНИЕ** **№ 22** **КАРАР**

09.11.2018 ел.

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 20 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 940 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 20 апрелендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертергә.

1. 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү чыгымнары елына айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә 6.72 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә.

2. 2018 елның 01 октябрендәге штат расписаниесен расларга һәм һәм яңадан исәплән чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының

Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 июнендәге 7 номерлы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http:/ sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы рәисе А.Р.Мияссарова